**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 1 июнь № 396

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында торак йортларның лоджияләренә һәм балконнарына пыяла кую турында» 2001 ел, 6 февраль, 55 нче карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3 нче пункттагы «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча ведомствога карамаган дәүләт экспертизасы идарәсенә» сүзләрен «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында табигый, техноген һәм биология-социаль характердагы гадәттән тыш хәлләр мониторингы, лаборатор тикшерү һәм прогнозлау территориаль системасын төзү турында» 2002 ел, 20 май, 277 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 24 апрель, 141 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында табигый, техноген һәм биология-социаль характердагы гадәттән тыш хәлләр мониторингы, лаборатор тикшерү һәм прогнозлау территориаль системасы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.2 нче пунктның сигезенче абзацындагы «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча ведомствога карамаган дәүләт экспертизасы идарәсе» сүзләрен «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр төзү дисциплинасын саклау һәм шәһәр төзү документларын эшләү турында» 2002 ел, 11 июнь, 329 нчы карарын үтәү барышы

хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 ел, 14 гыйнвар, 1 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә һәм Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә:»;

5 нче пунктның дүртенче абзацындагы «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча ведомствога карамаган дәүләт экспертизасы идарәсе тарафыннан» сүзләрен «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 1 ноябрь, 518 нче; 2005 ел, 6 декабрь, 574 нче; 2006 ел, 16 март, 103 нче; 2006 ел, 21 апрель, 201 нче; 2008 ел, 18 апрель, 239 нчы; 2008 ел, 22 декабрь, 911 нче; 2010 ел, 17 июнь, 482 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1034 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 30 сентябрь, 815 нче; 2012 ел, 10 август, 696 нчы; 2012 ел, 23 ноябрь, 1020 нче; 2013 ел, 18 март, 173 нче; 2013 ел, 25 июль, 525 нче; 2014 ел, 6 март, 141 нче; 2014 ел, 13 август, 586 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.2 нче пунктның егерменче абзацындагы «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча ведомствога карамаган дәүләт экспертизасы идарәсе тарафыннан» сүзләрен «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль-мәдәни өлкә объектларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында» 2006 ел, 4 декабрь, 596 нчы карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 нче пунктның беренче абзацындагы «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча ведомствога карамаган дәүләт экспертизасы идарәсе» сүзләрен «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

6 нчы пункттагы «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча ведомствога карамаган дәүләт экспертизасы идарәсенең» сүзләрен «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең» сүзләренә алмаштырырга.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларын финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт учреждениеләренең һәм дәүләт

унитар предприятиеләренең төп чараларына капитал салулар рәвешендә бюджет инвестицияләрен һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә субсидияләр күздә тота торган программаларны формалаштыру һәм тормышка ашыру тәртибен раслау турында һәм бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру буенча күчеш нигезләмәләрен билгеләү хакында» 2007 ел, 29 декабрь, 805 нче карары белән расланган Муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларын финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт учреждениеләренең һәм дәүләт унитар предприятиеләренең төп чараларына капитал салулар рәвешендә бюджет инвестицияләрен һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә субсидияләр күздә тота торган программаларны формалаштыру һәм тормышка ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.9 нчы пунктның беренче абзацындагы «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча ведомствога карамаган дәүләт экспертизасы идарәсе тарафыннан» сүзләрен «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 ел, 18 апрель, 246 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 февраль, 96 нчы; 2009 ел, 5 март, 125 нче; 2010 ел, 20 апрель, 278 нче; 2010 ел, 15 июнь, 477 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 24 март, 217 нче; 2011 ел, 12 август, 663 нче; 2011 ел, 8 сентябрь, 753 нче; 2011 ел, 31 октябрь, 899 нчы; 2012 ел, 27 апрель, 329 нчы; 2012 ел, 31 август, 743 нче; 2013 ел, 26 март, 203 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 831 нче; 2013 ел, 14 декабрь, 987 нче; 2013 ел, 31 декабрь, 1136 нчы; 2014 ел, 16 апрель, 249 нчы; 2015 ел, 25 февраль, 112 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.2 нче пунктның унбишенче абзацындагы «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча ведомствога карамаган дәүләт экспертизасы идарәсе тарафыннан» сүзләрен «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.

8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 6 февраль, б-152 нче боерыгына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

5 нче пунктагы «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча ведомствога карамаган дәүләт экспертизасы идарәсенә» сүзләрен «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә» сүзләренә алмаштырырга.

9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 22 апрель, 267 нче; 2014 ел, 1 октябрь, 708 нче; 2014 ел, 14 ноябрь, 876 нчы; 2014 ел, 12 декабрь, 977 нче; 2015 ел, 8 апрель, 231 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасының «Уңайлы мохит» ярдәмче программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

ярдәмче программаның IV бүлегендәге унөченче абзацның «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча ведомствога карамаган дәүләт экспертизасы идарәсе» сүзләрен «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

ярдәмче программага 2 нче кушымтада:

текст буенча «ТР ТһА буенча ДВЭИ» сүзләрен «ТР ТһА буенча ЭББДИ» сүзләренә алмаштырырга;

таблицадан соң унсигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ТР ТһА буенча ЭББДИ – Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе;».

10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында физик культура, спорт, туризмны үстерү һәм яшьләр сәясәтен тормышка ашыру нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 7 февраль, 73 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 9 апрель, 228 нче; 2014 ел, 1 ноябрь, 831 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында физик культура, спорт, туризмны үстерү һәм яшьләр сәясәтен тормышка ашыру нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасының «2014 – 2020 елларга физик культура һәм спортны үстерү» ярдәмче программасына 1 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешне кертергә:

5 нче пунктның «в» пунктчасында «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча ведомствога карамаган дәүләт экспертизасы идарәсенең» сүзләрен «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең» сүзләренә алмаштырырга.

11. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия гаиләсе өчен торак» программасын тормышка ашыру кысаларында вәкаләтле органнар билгеләү турында» 2014 ел, 14 июль, 495 нче карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 пунктның дүртенче абзацында «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча ведомствога карамаган дәүләт экспертизасы идарәсе» сүзләрен «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» сүзләренә алмаштырырга.

12. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелешләре Татарстан Республикасы бюджеты акчасын җәлеп итеп финанслана торган капиталь төзелеш объектларының смета кыйммәтен билгеләүнең дөреслегенә тикшерү үткәрү тәртибе турында» 2014 ел, 9 декабрь, 963 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пункттагы «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча ведомствога карамаган дәүләт экспертизасы идарәсе» сүзләрен «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Төзелешләре Татарстан Республикасы бюджеты акчасын җәлеп итеп финанслана торган капиталь төзелеш объектларының смета кыйммәтен билгеләүнең дөреслегенә тикшерү үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәнең 4 нче пунктында «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча ведомствога карамаган дәүләт экспертизасы идарәсе» сүзләрен «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» сүзләренә алмаштырырга.

13. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәяләр кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесен оештыру турында» 2015 ел, 20 февраль, 102 нче карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

автоном учреждениене гамәлгә куючының вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тормышка ашыра;

оештырылган вакыттан башлап, автоном учреждение проект документларына дәүләт экспертизасын һәм инженер тикшерүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын, Россия Федерациясе Шәһәр төзү кодексының 6 статьясындагы 1 өлешнең 5.1 нче пунктында күрсәтелгән объектларның проект документларына дәүләт экспертизасыннан һәм инженер тикшерүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасыннан тыш, үткәрүне гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков